МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 177/о

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«17» 10 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы белән расланган «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе

субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 27 декабрендәге 229/о номерлы, 2018 елның 11 апрелендәге 62/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның «17» 10 №177/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы белән расланган «Финансланучы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктның алтынчы абзацында «мәгълүматларны үз эченә ала» сүзләреннән алда «Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә» сүзләрен өстәргә, «6.1» саннарын «5.1» саннарына алмаштырырга;

1.6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).».»;

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Смета бәясен билгеләүнең төгәллеген тикшерү шартнамәдә каралган чорда уздырыла, ул 30 эш көненнән артыграк була алмый.»;

2.8 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) проект документациясе проект документациясенең эчтәлегенә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән составка һәм таләпләргә җавап бирмәгәндә, шул исәптән, әгәр проект документациясенең 9 яки 11 бүлеген

төзегәннән соң төзелешнең смета бәясен исәпләгәндә исәпкә алынган смета нормативлары һәм (яки) төзелеш ресурсларының смета бәяләре үзгәрсә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен смета документациясе, тикшерү уздыру өчен аны тапшыру датасына барлыкка килгән бәяләрне исәпкә алып, әлеге документациягә төзәтмәләр керткәннән соң тапшырыла; »;

2.16 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Смета бәясенә тикшерү уздыру өчен документлар электрон документлар рәвешендә тапшырыла, ә документларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булганда, – кәгазьдә.»;

3 бүлектә:

3.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Смета бәясенә тикшерү уздыру өчен документлар электрон документлар рәвешендә тапшырыла, ә документларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булганда, – кәгазьдә.»;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү.

Эксперт-башкаручы документациягә анализ ясый һәм смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета нормативларына, проект документациясендә каралган эшләрнең физик күләменә, конструктив, оештыру-технологик һәм башка карарларга туры килү-килмәвен билгеләү максатларында смета документациясендә булган исәпләмәләрне бәяли.

Конструктив карар бәясе нормативын смета нормативларының федераль реестрына кертү өчен смета документациясендәге исәпләмәләрне бәяләү аларның смета нормативларының федераль реестрына кертелгән бүтән смета нормативларына (шул исәптән элементлы смета нормаларына) туры килү-килмәвен билгеләү максатларында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә смета документациясенә үзгәрешләр кертү шартнамәдә каралган чорларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Әгәр дәүләт хезмәтен күрсәткәндә тапшырылган исәпләмәләрнең төгәл яисә төгәл булмавы турында йомгак ясарга мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (белешмәләрнең, тасвирламаларның, исәпләмәләрнең, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы яисә тулы булмавы) ачыкланса, өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәр җибәрелә һәм, зарурлык булганда, аларны бетерү чоры билгеләнә. Эксперт-башкаручы кисәтүләренә җавап һәр кисәтү пункты буенча язмача рәвештә әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә тапшырылырга тиеш, шулай ук электрон рәвештә төзәтелгән смета документациясе дә тапшырыла.

Эксперт-башкаручы смета бәясен ачыклауның төгәл яисә төгәл булмавына карата нәтиҗә ясый һәм моның өчен шәхсән җаваплы була, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләренә карап, бәяләмә уңай (төгәл булуы турында) яисә тискәре (төгәл булмавы турында) булырга мөмкин.

Эксперт-башкаручы капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, мәдәни мирас объектын саклау буенча

эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булмавы турында бәяләмә рәсмиләштерә, әгәр:

а) ачыкланган җитешсезлекләрне смета бәясен тикшерү процессында бетерүе мөмкин булмаса яки мөрәҗәгать итүче аларны билгеләнгән срокта бетермәсә;

б) смета документациясендә булган исәпләмәләр расланган, алар турындагы белешмәләр смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета нормативларына туры китереп башкарылмаса;

в) смета документациясендә проект документациясендә кабул ителгән эшләрнең, конструктив, оештыру-технологик һәм башка чишелешләрнең исәпләмәләрдә кулланылган физик күләмнәренең дөрес булмавына һәм (яки) нигезле булмавына бәйле хаталар ачыкланса.

Эксперт-башкаручы бәяләмә әзерли, бәяләмәне вакытында рәсмиләштергән өчен җавап бирә, аны, алга таба рәсмиләштерүгә тапшыру өчен, бәяләмәләр бирү бүлеге белгеченә җибәрә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе эксперт-башкаручы тарафыннан Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 29 мартындагы 655/пр номерлы боерыгы нигезендәге форма буенча бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: раслау өчен әзерлгән бәяләмә проекты.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамлангач егерме эш көне дәвамында башкарыла.»;

5 бүлектә:

5.2 пунктта:

3 пунктчада «каралмаган документларны тапшыруны» сүзләрен «тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны мөрәҗәгать итүчедән таләп иткәндә.»;

5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.7^1$- $5.7^2$ пунктлар өстәргә:

«$5.7^1$. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

$5.7^2$. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча блок-схема

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны һәм документларны техник хезмәткә җибәрү

↓

Техник хезмәт белгече тарафыннан белешмәләр бирү турында ВЭХС аша гарызнамәләр җибәрү һәм электрон рәвештә җаваплар алу

Техник хезмәт белгече документлар тупланмасының тулы булу-булмавын

Тапшырылган документлар җыелмасын тулыландыру зарурлыгы турында хат

Техник хезмәт белгече тарафыннан «ТР ДЭБКИ» ДАУ белән Мөрәҗәгать итүче арасында, дәүләт хезмәте күрсәтү бәясен билгеләп, хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә проектын әзерләү, шартнамәне Мөрәҗәгать итүчегә җибәрү

«ТР ДЭБКИ» ДАУ экспертиза хезмәте экспертлары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү

Бәяләмәләр бирү бүлеге белгече тарафыннан уңай (тискәре) бәяләмәне теркәүгә алу һәм бирү».